ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИКИФОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Карла Маркса, д.13, с. Никифорово, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422166

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НИКИФОРОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Карл Маркс ур., 3 нче йорт, Никифорово авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422166

тел.(факс): (85563) 2-42-38; e-mail:Nikifor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

от 18.09.2019 г №22

Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясының 1 пункты, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Никифорово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге башкарма комитеты турындагы Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРДЕ:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-Никифорово авылында Карл Маркс урамы, Сәртек авылында Муса Җәлил урамы юлларын вак таш белән ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү)

- Сәртек авылында су чыганагына павильон коймасы ясау һәм урнаштыру

-Никифорово һәм Сәртек авылларындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Мамадыш муниципаль районы
Никифорово авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе С.Н.Степанов